ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Югары Ослан муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» һәм «Шыланғы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Югары Ослан муниципаль районы составына керүче «Вахитов авыл җирлеге» һәм «Шыланғы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VI өлеш); 2013, № 7; 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

**«Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре**
**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
**10** - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның янәшә чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 5(40) -18(41) | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| 18(41) -35(42) | - Лаеш муниципаль районы |
| 35(42) -41(87) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 41(87) -37(38) | - Апас муниципаль районы |
| 37(38) -22(39) | - Кайбыч муниципаль районы |
| 22(39) -5(40) | - Зеленодольск муниципаль районы |

«Югары Ослан муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Иннополис шәһәре |
| 2 | Олы Мәми авыл җирлеге |
| 3 | Борнаш авыл җирлеге |
| 4 | Вахитов авыл җирлеге |
| 5 | Введенский Бистәсе авыл җирлеге |
| 6 | Югары Ослан авыл җирлеге |
| 7 | Канаш авыл җирлеге |
| 8 | Килди авыл җирлеге |
| 9 | Карагуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Куралово авыл җирлеге |
| 11 | Мәйдан авыл җирлеге |
| 12 | Макыл авыл җирлеге |
| 13 | Яр буе Морквашы авыл җирлеге |
| 14 | Түбән Ослан авыл җирлеге |
| 15 | Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге |
| 16 | Октябрь авыл җирлеге |
| 17 | Печище авыл җирлеге |
| 18 | Соболевский авыл җирлеге |
| 19 | Шыланoccы авыл җирлеге |
| 20 | Ямбулат авыл җирлеге |

»;

2) 5 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацта «600 м төньяк-көнчыгышта» сүзләрен «1360 м төньяк-көнчыгышта» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вахитов авыл җирлеге чиге Шыланӊгы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча уза, аннары «Идел буе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шыланӊгы участок урманчылыгындагы 54 нче урман кварталы буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 54 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, аннары 400 м көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 55 нче урман кварталы буйлап бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, инешне кисеп үтеп, 55 нче урман кварталы буйлап 200 м уза, аннары 250 м көнбатышка таба шушы урман

кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 450 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 200 м бара, аннары 150 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 100 м төньяк-көнбатышка таба 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м уза, 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 150 м бара, алга таба 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба һәм 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м уза, аннары, сынык сызык ясап, урман кварталының шушы аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м көнбатышка таба һәм 1,2 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 650 м көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м төньякка таба урман кварталының шушы аерымланган кишәрлеге буйлап, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 650 м көнбатышка таба, төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны һәм аның төбе буенча ага торган кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 250 м көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,0 км төньякка таба, 750 м көнбатышка таба, 500 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м көнбатышка таба, көньяк-көнбатышка таба «Идел буе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ключище участок урманчылыгындагы 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, алга таба 48 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м, көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м төньяк-көнбатышка таба һәм 600 м көньяк-көнбатышка таба, аннары 46 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш

чиге буйлап 700 м, көньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 200 м, «Казан – Ульяновск» – Кама Тамагы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 300 м көньяк-көнбатышка таба 46 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнчыгышка таба 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, шуннан соң 300 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 52 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм 1,5 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба 52 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап Вахитов, Шыланғы һәм Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

3) 20 нче кушымтаның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шыланғы авыл җирлеге чиге Вахитов авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шыланғы, Вахитов авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Нариман авылыннан 1360 м төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча уза, аннары «Идел буе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шыланғы участок урманчылыгындагы 54 нче урман кварталы буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 54 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, аннары 400 м көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 55 нче урман кварталы буйлап бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, инешне кисеп үтеп, 55 нче урман кварталы буйлап 200 м уза, аннары 250 м көнбатышка таба шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 450 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 200 м бара, аннары 150 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 100 м төньяк-көнбатышка таба 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м уза, 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 150 м бара, алга таба 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба һәм 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 150 м уза, аннары, сынык сызык ясап, урман кварталының шушы

аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м көнбатышка таба һәм 1,2 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 700 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көнбатышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 650 м көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м төньякка таба урман кварталының шушы аерымланган кишәрлеге буйлап, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 650 м көнбатышка таба, төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны һәм аның төбе буенча ага торган кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 250 м көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,0 км төньякка таба, 750 м көнбатышка таба, 500 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 150 м көнбатышка таба, көньяк-көнбатышка таба «Идел буе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ключище участок урманчылыгындагы 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 48 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, алга таба 48 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м, көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м төньяк-көнбатышка таба һәм 600 м көньяк-көнбатышка таба, аннары 46 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, көньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 200 м, «Казан – Ульяновск» – Кама Тамагы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 300 м көньяк-көнбатышка таба 46 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнчыгышка таба 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, 52 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, шуннан соң 300 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 52 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба һәм 1,5 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба 52 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.».

**3 статья**


Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты | Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ 74-ТРЗ

«Югары Ослан муниципаль районының «Вахитов авыл җирлеге» һәм «Шыланғы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләренең
**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Югары Ослан муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б – Вахитов авыл җирлегенең һәм Шыланғы авыл җирлегенең уртак чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Югары Ослан муниципаль районының Шыланғы авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге территориясе